ителде. Программа социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмалары тармагы инфраструктурасын үстерүгә, гражданнарның үзара татулыгына, милләтара һәм динара дуслыгына, җәмгыятьтә ришвәтчелеккә каршы тискәре караш формалаштыруга, мәдәният, сәнгать, иҗатта, өстәмә белем алуга, сәламәт яшәү образын һәм спортны пропагандалауга, аларны популярлаштыруга, инвалидларны социаль яраштыруга, ятимлекне кисәтүгә, аналар һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелде.

Татарстанда Татарстан Республикасы Президенты, хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары, республиканың социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмалар, ведомстволар һәм муниципаль иҗтимагый советлар, һөнәри берлекләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, академик берләшмәләр, шулай ук Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы һәм төбәк иҗтимагый палата вәкилләре катнашында социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның республика форумын уздыру мөһим традициягә әйләнде. Социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларга милек белән ярдәм күрсәтүдә 2015 елда социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның республика үзәген оештыру зур адым булды. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы уздырган конкурс кысаларында социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларга биналар бушлай бирелә башлады. Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте институтын үстерүгә керткән өлеш өчен ТР Президенты премиясен раслау турында ТР Президенты указы –социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның дәүләт партнеры булуын раслаучы тагын бер фактор.

Кешенең һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен нәтиҗәле яклау максатыннан күпьеллык эш тәҗрибәсенә, иҗтимагый хокук яклау оешмалары белән хезмәттәшлек һәм алар белән төзелгән килешүләргә нигезләнеп, Вәкил үзенең хокук яклау функциясен дәвам итә.

2016 елда «Татарстан Республикасында коммуналь-торак хуҗалыгы өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге»нең (башкарма директоры –

Романов Дмитрий Сергеевич) «Социаль тернәкләндерү һәм ярашу үзәге» соцИаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган автоном оешма (генераль директоры – Гайнетдинов Азат Галимҗан улы) белән партнерлык мөнәсәбәтләре көйләнде.

Республика социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмалар партнерлыгында Вәкил аеруча зур игътибарны хокукый белемне күтәрүгә һәм гражданнарга юридик хезмәт күрсәтүгә бирә. Халык белән эшләүдә «Кайнар элемтә»ләр, «Хокукый ярдәм көннәре», Хокукый белем мәктәбе дәресләре, курслар һәм лекцияләр уздыру, шулай ук методик белешмәлекләр әзерләү кебек эш формаларын куллану практикада үзен яхшы күрсәтә.

Менә мәсәлән, «Россия пенсионерлары берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге белән берлектә (идарә рәисе – Любовь Николаевна Мишина) даими рәвештә хокукый белем мәктәбе дәресләре, Казанда һәм республика районнарында (ТР Адвокат һәм Нотариаль палаталары ярдәме нигезендә) хокукый ярдәм көннәре оештырыла.

Хөкем җәзасын үтәп кайтучы затларны кабул итү, колонияләрдә хокукый ярдәм көннәре, шулай ук Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту изоляторларында, СИЗО һәм колонияләрдә яшәү шартларын тикшерү Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе хезмәттәшлегендә үтә.

«Юридик клиника» мигрантларга һәм Татарстан Республикасыныц социаль яктан якланмаган халкына хокукый ярдәм итү үзәге (җитәкчесе – Балафендиева Гөлия Гомәр кызы) һәм «Яца гасыр» автоном хәйрия коммерциягә кагылышы булмаган оешманың (генераль директоры – Таишева Лилия Әхәт кызы) үзара актив хезмәттәшлеге аркасында миграцион мөнәсәбәтләрнең бөтен тармагы – хезмәт мигрантлары, качаклар, теләнчеләр, илдән чыгарылып җибәрелгән чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар игътибар үзәгендә тора.

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләгәндә «Акцент» хокук яклау группасы (җитәкчесе – Мөхәммәтҗанов Булат Салихҗан улы), «Добро даром»

хәйрия фонды (җитәкчесе – Хәкимуллин Раушан Рафикъ улы) һәм башкалар белән үзара хезмәттәшлек итә.

ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов 2016 елның 21 сентябрендә ТР Дәүләт Советына юлламасында социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларга, халыкка социаль хезмәт күрсәтүне дә кертеп, дәүләт функцияләрен тапшыру юлында кыюрак барырга кирәклеген билгеләде. Әгәр РФ субъектлары тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итсәк, социаль-иҗтимагый хезмәтләрне, шул исәптән норкоманнарны тернәкләндерү, инвалидларга өйдә ярдәм күрсәтү, гражданнарга һәм балаларга ашыгыч социаль хезмәтләрне Пермь краеның дәүләтнеке булмаган оешмалары күрсәтә, биредә социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмалары проектларын финанслау озак вакытлы финанслауга күчерелгән. Пермь крае Социаль үсеш министрлыгы линиясе буенча иҗтимагый оешмаларны һәм аларның хисапларын финанслауның ачык процедуралары оештырылган.

Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмалар социаль һәм иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә катнашмыйлар диярлек. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы төп проблемалар итеп социаль өлкәдә дәүләтнеке булмаган тармак үсеше өчен институциональ нигезләрнең булмавын, социаль хезмәтләр күрсәтү системасында катнашу өчен социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмалар үсешенең тиешле дәрәҗәдә булмавын, шул исәптән күп кенә коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның даими эшкә әзербулмавын, коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларда квалификацияле белгечләрнең, шул исәптән финансларның тотрыксызлыгын, социаль хезмәтләр базарына чыгу өчен социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның белем бирү системасының булмавын атады.

Бүгенге көндә, безгә калса, социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның кадрлар потенциалын үстерү, аларның хокукый һәм мәгълүмати яктан белем алуы, иң яхшы практикаларны тарату, социаль юнәлештәге коммерциягә кагылышы булмаган оешмаларның халыкка социаль

юнәлештәге хезмәтләр күрсәтү сыйфатын, гомумән алганда, күтәрү ихтыяжы бар.

Татарстан Республикасының алга таба социаль-икътисади үсеше өчен кеше һәм гражданнар хокукларын яклау эшенә социаль һәм гражданлык ягыннан актив халыкны күбрәк җәлеп итеп, социаль әһәмияте булган проектларны тормышка ашыру турында мәгълүматларны республика массакүләм мәгълүмат чараларында киңрәк яктыртуга игътибар бирергә кирәк.

## Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын яклау

Һәр кешенең тормыш дәрәҗәсе аны хезмәт базарында тормышка ашыру, алына торган керемнәр, шул исәптән эш хакы дәрәҗәсе белән өзлексез бәйләнгән. Теләсә кайсы гаиләнең иминлеге аның күләменнән, үзвакытында, даими алуыннан тора.

Социаль-икътисад мониторингы буенча Татарстан Республикасы Комитеты мәгълүматларыннан чыгып, шундый нәтиҗә ясарга була: социаль минимумнан түбән (минималь куллану бюджеты, шулай ук яшәү минимумы) уртача хезмәт хакы түләүче эре һәм урта предприятиеләренең саны кимүе күзәтелде.шулай ук рәсми статистика мәгълүматларына караганда узган 2016 елда 2015 ел белән чагыштырганда күп булмаса да, реаль хезмәт хакы күләме артты.

Шул ук вакытта эш хакын вакытында түләмәү республикада элеккечә кискен проблемаларның берсе булып кала. Хисап тоткан авыл хуҗалыгы, ау һәм агач әзерләү, эшкәртү оешмалары һәм предприятиеләрендә эш хакы буенча кичектерелгән бурыч 2017 елның 1 гыйнварына, Татарстанстат мәгълүматларына караганда 12 миллион 636 мең сум тәшкил иткән. Ел нәтиҗәләре буенча эш хакы буенча иң күп әҗәтлеләр: «Ак барс Буа» ширкәте (Буа районы) – 3,863 миллион сум, «Фон-Строй» җәмгыяте (Казан шәһәре) – 3,325 миллион сум, «Нефтехимзаводстрой» төзелеш идарәсе (Түбән Кама

районы) – 2,435 миллион сум, «Нәүрүз» җәмгыяте (Әгерҗе районы) – 1,523 миллион сум, «Ак барс Кайбыч» 2 нче филиал (Кайбыч районы) – 1,490 миллион сум, шуңа 893 эшче вакытында эш хакы ала алмаган.

Эш хакын вакытында түләмәү фактлары масштабын контроль-күзәтчелек органнарының статистика мәгълүматлары да дәлилли. Татарстан Республикасының дәүләт хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда 2016 елда дәүләт инспекторлары таләбе буенча кичектерелгән эш хакы 14320 хезмәткәргә түләнгән. Түләүләрнең гомуми суммасы 219 миллион 802,04 мең сум.

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматларына караганда. Хезмәткәрләрнең эш бирүчедән эш хакын бары судка, аннан суд пристав-башкаручыларына мөрәҗәгать иткәч кенә алу очраклары арткан. 2016 елның 12 аенда гомуми суммасы 205 миллион 525 мең сум булган 7503 үтәү карары ябылган. (2015 елда – гомуми суммасы 83 миллион 426 мең сум булган 5486 үтәү карары ябылган булган).

Бурычның төп сәбәбе – предприятиенең акчасы юклык. Шуның белән бергә, тикшерү органнары эш хакын түләмәүнең сәбәбе оешма җитәкчесенең үз кесәсен яратуы яки явыз нияте икәнен ачыклаган, шуның нәтиҗәсендә җинаять эшләре ачылган. 2016 елда Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Ттатарстан Республикасындагы тикшерү идарәсе тикшерү бүлекчәләре эш хакы, пенсияләр, стипендияләр, пособиеләр һәм башка социаль түләүләр белән бәйле 52 җинаять эше ачкан, шулардан 10 җинаять эше судларга җибәрелгән, тагын 31 җинаять эше туктатылган. Шулай итеп, практика күрсәткәнчә, кардиналь чаралар күрү оешмалар җитәкчеләренә хезмәткәрләренә эш хакы түләү өчен акча эзләргә булышлык итәргә мөмкин. Ләкин мондый инициативаның булмавы да ихтимал. Эш хакы буенча бурычны түләү турындагы мәсьәлә оешма җитәкчесенә карата җинаять эше ачылып та хәл ителмәскә мөмкин.

Мәсәлән, узган ел ООО «Агрызская МСО» җәмгыяте җитәкчесе 2014 елның октябреннән 2015 елның февраленә кадәр хезмәт хакын өлешчә түләмәү

аркасында суд карары белән Россия Федерациясе Җинаять кодексының 145.1 маддәсе 1 өлешендә каралган җинаять кылуда гаепле дип табылган. Әгерҗе районы прокуратурасы мәгълүматларына караганда, «Агрызская МСО» җәмгыяте җитәкчесен җинаять җаваплылыгына тарту 16 хезмәткәре алдында 379083,20 сум күләмендә бурычы булу белән бәйле.

Вәзгыятьне өйрәнү вакытына шул ачыкланды, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы суд приставлары хезмәтенең территориаль бүлегендә прокурор гаризалары буенча суд актлары нигезендә кузгатылган эш хакын буенча бурычны кайтару турында нибары ике үтәү карары гына булган. Әлеге үтәү карарлары буенча акча алынган. Шул ук вакытта судка яки прокуратурага мөрәҗәгать итмәгән калган 14 хезмәткәргә хезмәт хакын түләү мәсьәләсе хәл ителмәгән. Алга таба хәл дә яхшырмаган. Җинаять эше буенча суд барышында «Агрызская МСО» җәмгыятенең банкротлыкка чыгару процедурасы булмаганлыктан асылда эшен туктатуы, табышы да булмавы ачыкланган.

Хезмәткәрләрнең үз вакытында судларга яки контроль-күзәтчелек органнарына мөрәҗәгать итмәве берничә сәбәп белән аңлатылырга мөмкин (сәламәтлек торышы, эш бирүченең бәхәсне тыныч юл белән хәл итәргә үгетләве һәм башкалар). Намуссыз эш бирүчеләр хезмәткәрләрнең пассивлыгы яки ышанычыннан файдаланып, озак вакытлар үз вазифаларын үтәүдән качып йөрергә мөмкин. Һәм монда безнең карашка оешма җитәкчесен җинаять җаваплылыгына тарту хезмәткәрләренә бурычын түләү теләген бетерергә мөмкин, ул җитди җәза алган бит инде.

Вәкил фикеренчә, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 145.1 маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган очракларда эш хакы буенча бурычны түләү судта эш каралганчы ук өстенлекле максат булырга тиеш, ә гаепләү карары чыгару түгел. «Җинаять эше бар, акча юк» кебек хәлләрдән качу өчен, оешма җитәкчесе белән сөйләшкәндә компетентлы органнар бурычны бетерүгә юнәлтелгән чараларның конкрет планын эшләп, шуларны контрольдә тотса яхшырак булыр иде. Әгәр предприятие җитәкчесенең бурычын кайтарырга теләге юк, ләкин бәйге производствосы ачылмаган һәм бурычлы-оешма

«Банкротлык турында» 2002 елның 26 октябрендә чыккан 127 нче федераль законда каралган тәртиптә бурыч буенча исәп-хисап ясамый икән, килеп туган хәлдә предприятиеләр хезмәткәрләре белән киң аңлату эшләре алып бару максатка ярашлы булыр иде.

2016 елда тулысынча хезмәт хакы түләмәү белән бәйле шикаятьләрне караганда тагын шул ачыкланды: эш хакын акчалата түләмәү өлеше арту; гамәлдәге законда каралган тотып калулар булганда эш хакы түләгәндә тотып калуларның гомуми күләмнән артып китү кебек хокук бозулар бар.

Узган чорда Вәкилгә даими рәвештә гражданнардан эшкә урнаша алмау, шул исәптән мәшгульлек үзәкләре аша да эшкә урнаша алмау турында мөрәҗәгатьләр керде. Әлеге мөрәҗәгатьләрне карау, әлеге тема буенча башка чаралар үткәрү кебек үк гражданнарның хезмәт эшчәнлеге һәм эш урыны сайлау хокукларын тормышка ашыруда дәүләт гарантияләрен көчәйтү кирәклеге турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Хәлне анализлау шуны күрсәтә, ел саен булышлык күрсәтүне үтенеп мәшгульлек хезмәте органнарына эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче меңнәрчә татарстанлы мөрәҗәгать итә. 2016 ел дәвамында Татарстан Республикасының мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләрендә теркәлгән һәм эшсез дип танылган гражданнар саны 13799 кешедән 18531 кешегә кадәр булды. Эшсез гражданнарның бер өлеше эш табуда зур мөмкинлекләр биргән «Эшсез гражданнарны профессиональ өйрәтү һәм өстәмә һөнәри белем бирү» дәүләт хезмәтеннән файдаланды. Узган елның 11 аенда 8060 кеше профессиональ өйрәнүгә һәм өстәмә һөнәри белем алуга керешә. Әйтергә кирәк, яңа һөнәри күнекмәләр тулаем алганда нәтиҗәле булды, шул исәптән эшкә урнаштыруның өстәмә гарантияләре билгеләнгән гражданнар өчен дә. Әйтик, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 369 инвалид һөнәри белем алган, һөнәри белем алуны тәмамлаган кешеләрнең 72,3 проценты эшкә урнашкан; иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәрдән 51 кеше яңа эшкә өйрәнгән,

шуларның 80 проценты эшле булган; хәрби хезмәттән киткән 50 кеше кабат һөнәри белем алып, шуларның 84,1 проценты эшкә урнашкан.

Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә максатка ярашлы дәүләт сәясәте булуга карамастан, гражданнарның эш эзләве белән бәйле хокук бозулар да бар. Мәсәлән, Казан, Әлмәт, Яшел Үзән шәһәрләренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрен тикшерү шуны күрсәтте: эшкә алудан баш тартуның сәбәпләренең берсе бары гражданның элек хөкем ителүе. Бу уңайдан шуны искәртеп узыйк, гамәлдәге законнар шушы нигездә эш бирүче вәкиле эшкә алудан педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнергә дәгъва итүчене генә кире кага алу очракларын күздә тота. Асылда мәшгульлек органыннан юллама белән килеп «җыештыручы», «урам себерүче», «йөк төяүче» вазифаларына урнашканда эшкә алудан баш тарту очраклары бар. Тикшерү барышында шулай ук эш эзләүченең тәҗрибәсе булмау аркасында эшкә урнаша алмау фактлары да бар, һөнәри стандартларга ярашлы рәвештә ул таләп ителмәскә дә мөмкин. Яшь - тагын бер дискриминация төре, эш эзләүчене олыгаеп килүе аркасында урындагы вазифага яки эшкә алмау очраклары бар.

Эшкә кабул итүдән нигезсез баш тарткан өчен граждан судка да бирә ала. Әмма һәр эш эзләүче булган урынга суд авырлыклары аша дәгъва итмәячәге дә ачык. Шуңа күрә дәүләт органнары артык сайланучан эш бирүчеләргә кандидатны эшкә алганда хокукларын кысу гамәлләрен бетерүгә юнәлтелгән чаралар күрсә, күпкә нәтиҗәлерәк булыр иде.

Компетентлы органнар әлеге хокук бозуларны бетерү белән шөгыльләнми дип исәпләү дөрес булмас иде. Проблеманы анализлау бу җәһәттән хезмәт законнарын бозучы эш бирүчеләргә тиешле тикшерүләр нәтиҗәләре буенча прокурор чаралары күрелүен күрсәтте. Шуның белән бергә, эш эзләүче һәм эш сыйфатлары белән бәйле булмаган сәбәпләр буенча эш бирүче кире каккан гражданнарның хезмәткә хокукларын өстәмә яклау механизмнары кирәк. Әлеге хәлләрне киметү өчен ведомствоара эшне җайга салу зарур. Халыкны эш белән тәэмин итү органнары эшкә алганда законсыз бар тартуларны күреп, аңлату эшләре белән генә шөгыльләнмичә, зур активлык

күрсәтеп, хокук бозучылар турында мәгълүматны тикшерү органнарына тапшырырга тиеш. Ахыр чиктә мондый һәр хокук бозу халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү буенча дәүләт сәясәте нигезләренә каршы килә һәм тиешле хезмәтләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсен киметә.Эш урыннары булу турында мәгълүмат урнаштырган эш бирүчеләр белән аңлату эшләре алып бару шулай ук мөһим юнәлеәләрнең берсе булып тора. Теге яки бу кандидатны эшкә алмау хезмәт законннары положениеләрен белмәүдән дә килеп чыгарга мөмкин.

Әлеге докладта тасвирланган проблемалы мсәьәләләрне хәл итү өчен контроль-күзәтчелек һәм хокук саклау органнарының тәэсирле чаралары да, гражданнарның хезмәткә хокукларын бозуга юл куйган эш бирүчеләргә карата дәүләт органнары тарафыннан аңлату эшләре үткәрү дә мөһим. Вәкил фикеренчә, системалы эш алып бару кеше үзен намуссыз эш бирүче гамәлләреннән сакланмаган дип хис иткән очракларны киметер иде.

## Гражданнарның торакка хокукларын яклау

Республикада торак төзү темплары югары булып кала бирә. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2016 елда республикада 2 миллион 406,5 мең квадрат метр торак сафка бастырылган.

Торак төзелеше программаларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә күп квартирлы йортларда 18550 квартира, шул исәптән, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» программасы буенча 5816 квартира, 9560 шәхси торак йорт төзелгән.

2016 елда 407 Бөек Ватан сугышы ветераны, 311 ятим, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм бала, 42 биш һәм аннан да күбрәк балалы гаилә, 81 яшь гаилә, 19 чернобыльче, 34 күченеп кайтырга мәҗбүр булучы, 3 Ерак Төньяктан кайтучы, 6 хәрби хезмәттән азат ителгән граждан торак белән тәэмин ителгән.

Ел нәтиҗәләре буенча, 6 проблемалы йорт тапшырылган, 1097 өлешче (өлешләп төзүдә катнашучы) яңа квартираларына күчкән. Шуның белән бергә алданган өлешчеләр проблемасы элеккечә үк актуаль булып кала.

Магистраль торба үткәргечләр саклау зонасы чикләрендә урнашкан торак йортларны сүтү проблемасы кискен калкып чыкты. 1999 елның 31 мартында дөнья күргән «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 69 нчы федераль закон нигезендә магистраль торба үткәргечләр зонасында объектлар булырга тиеш түгел. Узган елда «Газпром Трансгаз Казань» җәмгыятенең дәгъва гаризалары буенча суд актларына ярашлы рәвештә Казан читендә урнашкан Салмачи, Яшел Үзән районының Осиново бистәсендә яшәүчеләргә карата шундый йөкләмә куелды.

Сафка бастырылган, суд карарлары буенча сүтелергә тиешле йортларның үзбелдеклеләнеп төзелгән корылмалар булмавын әйтергә кирәк. Җир участокларын һәм аларда торак төзү өчен рөхсәтне җирле үзидарә органнары биргән.

Вәкил яшәүчеләргә бердәнбер торакларын югалту куркынычы янаганлыктан, «Газпром Трансгаз Казань» җәмгыяте адресына торак йортларны сүтү турында суд карарларын үтәүне башкармыйча, мәсьәләне хәл итүнең башка мөмкинлекләрен карау тәкъдиме белән чыкты.

Хәлне алга таба өйрәнү нигезендә шул ачыкланды, «Газпром Трансгаз Казань» һәм җирле үзидарә органнары торба үткәргечнең факттагы урнашу материалларын тапшыру һәм тапшырылган материалларны районнарның җирдән файдалану карталарына кертү буенча РФ Энергетика-ягулык министрлыгының 1992 елның 29 апрелендә расланган магистраль торба үткәргечләрне саклау кагыйдәләрендә һәм РФ Госгортехнадзорның 1992 елның 22 апрелендә чыккан 9 нчы карарында каралган үз вазифаларын башкаруны төрлечә бәяләгәннәр.

«Газпром Трансгаз Казань» җәмгыяте мәгълүматы буенча, саклау зонасына керүче коммуникацияләр, объектлар, торба үткәргеч (башкарма сьемка) торышы турындагы материаллар җирле хакимият һәм идарә

органнарына тапшырылган. Әлеге позицияне суд инстанцияләре дә яклаган. Үз чиратында, җирле үзидарә органнары саклау зоналары чикләре турында тулы мәгълүмат булмавын ассызыклый.

Һәр як үз позициясен дөрес дип саный, ләкин ахыр чиктә әлеге вәзгыятьтә авыр хәлдә калган гражданнар зыян күрә, шул исәптән гамәлдәге закон нигезендә сүтү турында карар чыгару өчен минималь ераклыктагы кагыйдәләр һәм төзү нормаларында билгеләгән бары газ белән тәэмин итү системасы объектларына якын бина, корылма төзү факты гына мөһим булу аркасында.

Вәкил фикеренчә, җирле үзидарә органнары магистраль торба үткәргечләр саклау зоналарында торак төзү өчен җир участоклары бирү очракларына юл куймас өчен тиешле чаралар күрергә тиеш. Саклау зоналары чикләре турында мәгълүматлар җитәрлек булмаганда аларны «Газпром Трансгаз Казань» җәмгыятеннән соратып алырга кирәк. Мондый хәлләрдә алар гражданнарга йортларын һәм җир участокларын калдыру таләбе кую юлы белән түгел, бәхәсне судта яки муниципалитет белән магистраль газүткәргечләрдән файдаланучы оешма арасында килешенгән гамәлләр юлы белән хәл ителсә, максатка ярашлы булыр иде.

Республика торак сәясәтендә авария хәлендәге торакны бетерү мөһим юнәлеш булып тора. Аварияле торак фондыннан халыкны күчерү программасы буенча 2012 елның 1 гыйнварына кадәр 1323 күпквартирлы йорт авария хәлендә дип танылган.Узган ел ахырына 872 торак йорттан яшәүчеләрне күчерү төгәлләнгән.

Авария хәлендә сүтәргә тиешле дип табылган йортларда яшәүче кайбер гражданнар өчен милек хокукында, социаль ипотека килешүе шартларында башка торакка күчерү перспективасы яки аварияле торак өчен тәкъдим ителә торган акчаның яңа фатир алырга җитмәве борчу тудыра. Вәкил адресына аварияле торактан күчерелгән һәм социаль ипотека килешүе төзегән гражданнардан матди хәлләрен начарайтуга китергән вакыйгалар аркасында айлык түләүләрне кичектереп тору яки күләмен киметү турында мөрәҗәгатьләр даими килеп тора. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт

торак фонды» коммерциячел булмаган оешманың социаль ипотека килешүе буенча бурычы булган гражданнарга карата төп бурычны гына түгел, читләр акчасыннан файдаланган өчен процентларны да түләтү таләбе белән дәгъва гаризалары бирү практикасын исәпкә алсак, әлеге мәсьәлә бик мөһим. Вәкил фикеренчә, ул аварияле йорттан күчерелүчеләрнең генә түгел, аз тәэмин ителгән дип танылмаган, әмма булачак квартирага түләүләр гаиләнең уртак табышының сизелерлек өлешен тәшкил иткән социаль ипотекада башка катнашучыларның да торакка хокукларын тормышка ашыруга кагыла.

Билгеле, килешү мөнәсәбәтләренә кереп, килешүдә катнашучылар аны үтәү бурычын алалар. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы законында торак төзелеше үстерүдә дәүләт яклавы гражданнарның табышын исәпкә калып тормышка ашырыла дип билгеләнгән.

Гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итүдә өстәмә механизм сыйфатында Вәкил нигезләүләр исемлеген киңәйтергә тәкъдим итә, аның буенча торак социаль ипотека программасында катнашучыларга, аларда торак сатып алу өчен житәрлек өстәмә финанс ресурслары барлыкка килү белән алга таба милеккә хокукын саклап, найм шартларында срокны чикләмичә тапшырыла алыр иде.

Вәкилгә Казан хакимияте башлыгының карары белән 1990 елларда яки 2000 еллар башында жимерек дип танылган, әмма федераль законда билгеләнгән тәртиптә бинаны бәяләү процедурасы үткәрелмәү аркасында авария хәлендәге яки сүтелергә тиешле дигән статус алмаган йортларда яшәүчеләрдән шикаятьләр килә. Нәтиҗәдә андый йортларда яшәүчеләр Россия Федерациясе Торак кодексында каралган торакка хокукны тәэмин итү чараларына өмет итә алмый.

2016 ел ахырына Казан шәһәре башкарма комитеты мәгълүматлары буенча шундый 174 йорт бар һәм аларда 800 дән артык гаилә яши. Кайвакыт йортларның торышы шундый хәлдә була, Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары аерым очракларда үзләре суд аша авария хәлендәге йортларда яшәүчеләрне күчерүгә ирешәләр. Мондый чаралар күрү билгеле,

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итүгә юнәлтелгән. Ләкин андый йортларда яшәү куркынычы дәрәҗәсе уңаеннан гомуми хәлне бәяләү юк.

Вәкил Татарстан Республикасы дәүләт хезмәт инспекциясенә Казан шәһәре башкарма комитеты белән берлектә, торак йортны яшәү өчен яраксыз һәм күп квартирлы йортны авария хәлендә һәм күчерелергә тиешле дип тану турындагы Россия Федерациясе хөкүмәте 2006 елның 28 гыйнварында раслаган 47 нче Положениегә ярашлы рәвештә, дәүләт торак күзәтчелеге органы заключениесе нигезендә мондый йортларны этаплап тикшерү буенча эшне оештырырга тәкъдим итә. Безнең карашча, төп игътибар яшәүчеләре тузган торак фондын бетерү программасы һәм Казан шәһәренең тузган тораклы кварталларын төзекләндерү чикләрендә өлешчә күчерелгән йортларга бирелергә тиеш. Торак йорттагы буш бүлмәләр спиртлы эчемлекләр яки наркотик матдәләр куллану урыны, шулай ук тузган йортларда һәм күрше йортларда яшәүчеләрнең тормышына һәм саулыгына зыян китерердәй башка тискәре күренешләр, янгыннар барлыкка китерүче куркыныч урын булып тора.

Узган елда Вәкил адресына сафка бастырылган социаль ипотека программасы буенча төзелгән аерым йортларның төзү сыйфатыннан зарланган шикаятьләр керде.

Мәсәлән, Вәкил адресына бетон плитәләр кушылган җирләрдән, пыялалы балконнардан су агуы турында Казан шәһәренең Актай урамы 47 нче йортында яшәүчеләрдән шикаятьләр керде. Гарантияле срок чикләрендә подряд оешмалары эш кимчелекләре күзәтчелек органнары һәм идарәче оешма тарафыннан теркәлсә дә, төзелеш кимчелекләрен бетерү буенча чаралар күрмәгән.

«Казан йортлар төзү комбинаты» төзелеш компаниясе дә, Казан шәһәренең Глушко урамы, 4 нче йорты буенча гарантия йөкләмәләре булса да күчү балконнарының идән җәймәләре җимерелү, штукатур катламы кубу кебек төзелеш кимчелекләрен бетермәгән. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы

мәгълүматы буенча, әлеге төзелеш оешмасы эшен туктаткан, квартирларны карау яңа подряд оешмасына бирелгән.

«Казаньцентрстрой» төзелеш оешмасы гарантия йөкләмәләре буенча, Казан шәһәренең Глушко урамы, 6 нчы йорт адресы буенча булган ярыкларны бетерергә тиеш, әмма мөрәҗәгатьләр буенча тиешле эшләр башкарылмаган. Төзелеш оешмасына төзелеш кимчелекләрен бетерү таләбе суд тәртибендә башкарылды.

Подряд оешмалары кимчелекләрне судтан тыш төзәтүдән качкач,гражданнарның судка мөрәҗәгать итәргә мәжбүр булулары, шулай ук төзелеш кимчелекләрен бетерүне йөкләүче суд практикасы булу фактларын исәпкә алып, Вәкил «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасына объект (торак йорт) төзүгә подряд килешүләрендәсубподрядчыларны инвестор-төзүче булган оешма белән килештереп кенә төзергә рөхсәт итү турындагы пунктны карарга тәкъдим итә. Шул ук вакытта социаль ипотека программасы буенча торак йортлар төзүгә элек төзелгән йортларда гарантияле хезмәт күрсәтү буенча йөкләмәләрен үтәмәүче подряд оешмаларны кертмәү яхшы булыр иде.

Россия Федерациясендә дәүләт һәм муниципаль торак фондына караган торакны хосусыйлаштыру вакыты берничә мәртәбә озынайтылды. Әлег мәсьәлә Вәкилне шунысы белән кызыксындырды, Казан шәһәрендә яшәүче Казан шәһәре башкарма комитетының квартираны хосусыйлаштыруга документлар биргән гражданнан элек йортта яшәп, аннан исәптән төшкән балигъ булмаган бала өчен опека һәм попечительлек органнары рөхсәтен күрсәтү бурычын билгеләгән норматив актын кире кагу турында Татарстан Республикасы Конституция Судына шикаять язды.

2016 елның 21 октябрендә Татарстан Республикасы Конституция Суды әлеге норма Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән карар чыгарды. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция Суды балигъ булмаган бала исәптән төшкән торак йортны хосусыйлаштыруга опека һәм попечительлек органнары рөхсәте, әгәр торак йортны хосусыйлаштыру элек

исәптән төшкән, әмма аннан файдалану хокукын югалтмаган балигъ булмаган бала катнашыннан башка башкарылганда гына таләп ителергә мөмкин икәнен билгеләде.

Үз чиратында, җирле үзидарә органнарының 2016 ел ахырына биргән мәгълүматларына караганда, гражданнарның муниципаль торакны милек итеп теркәү документлары биргәндә, торак йорттан балигъ булмаган бала файдалана ала яки аларны исәптән төшергәч файдалану хокукын югалта дигән очраклар булмаган. Шул уңайдан, федераль законга ярашлы рәвештә хосусыйлаштыру срокларын озынайту очракларында Вәкил Казан шәһәре башкарма комитетына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2012 елның 28 июнендә чыккан 4310 нчы карары белән расланган гражданнарның милкенә (хосусыйлаштыру) торак йортларны тапшыруга килешүләр төзегәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтү Административ регламентына Казан шәһәре муниципаль торак фонды торагын милек итеп теркәү турында гариза биргән гражданнарга элек торактан балигъ булмаган бала исәптән төшерелсә, опека һәм попечительлек органнары рөхсәтен күрсәтүен күздә тоткан өстәмә кертүне тәкъдим итә.

## Сәламәтлек саклауга һәм медицина хезмәтенә хокукны яклау

Сәламәтлек саклауга, квалификацияле һәм үзвакытында күрсәтелгән медицина ярдәменә хокук — кешенең иң мөһим социаль хокукларыннан берсе.

Республикада сәламәтлек саклау учреждениеләренең матди базасын ныгытуга, яңа медицина үзәкләре ачуга, югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне үстерүгә юнәлтелгән масштаблы программалар тормышка ашырыла.

Кабул ителә торган чаралар нәтиҗәсендә республикада демографик вәзгыять яхшыру күзәтелә.

Шуның белән бергә Вәкил адресына, Татарстан Республикасы «Халык

контроле» дәүләт мәгълүмат системасы сайтының «Хастаханәләр һәм сырхауханәләр» бүлегенә, хокук саклау иҗтимагый оешмаларына, массакүләм мәгълүмат чараларына гражданнарның медицина ярдәменә хокукларын саклауга кагылышлы проблемалары турында мәгълүматлар килү дәвам итә. Шулар арасында республиканың аерым муниципаль районнарында тудыру бүлекләре, Казан шәһәрендә теш дәвалау поликлиникалары ябылу, шулай ук медицина учреждениеләренең яшәү урыннан ерак булуы уңаеннан тиешле медицина ярдәме алуга хокуклар бозылу турындагы мәсьәләләр бар. Шулай ук гражданнарны дарулар белән тәэмин итү, амбулатор-поликлиника челтәре, кан тамырлары үзәкләре эшенә кагылышлы сораулар кузгатыла.

Гражданнарны дару препаратлары белән тәэмин итү Татарстан Республикасы территориясендә бушлай медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләрен тормышка ашыру буенча сәламәтлек саклау органнарының мөһим бурычы булып тора.

2016 елда республиканың кайбер медицина учреждениеләрендә (Азнакай, Алабуга, Яшел Үзән, Мамадыш районнарында) дарулар булмаганлыктан, баш мие кан әйләнеше кискен бозылган авыруларга аларны туганнары үзләре сатып алу очраклары ачыкланды. Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән белдерүләрне карау нәтиҗәсендә «Аксубай үзәк район хастаханәсе» учреждениесенең, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» учреждениесенең, Чаллы шәһәре йогышлы авырулар хастаханәсенең стационарда ятучы авыруларны дару препаратлары белән тәэмин итмәү фактлары беленде, ахыр чиктә гражданнар үзләре яки аларның туганнары күрсәтелгән учреждениеләр җитәкчелегенең дару препаратлары белән өзлексез тәэмин итү буенча канәгатьләнмәслек эшләве аркасында даруларны үз акчаларына сатып алырга мәҗбүр булган. Вәкил фикеренчә, әлеге мәсъәләне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы контрольгә алырга тиеш.

Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән белдерүләрне тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтте:

телефон һәм электрон элемтә чараларыннан файдалану, башка формалар һәм ысуллар булуга карамастан, элеккечә үк амбулатор-поликлиника челтәре белгечләренә (педиатр, невролог, кардиолог, окулист, эндокринолог) язылу проблемасы бар. Бу өлешчә сәламәтлек саклау учреждениеләрендә табиблар җитмәү белән аңлатыла. Перинаталь үзәкле Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсендә, Бөгелмә үзәк район хастаханәсендә, Казан шәһәренең 2 нче һәм 6 нчы балалар шәһәр поликлиникаларында, Чаллы шәһәренең 3 нче, 5 нче, 6 нчы балалар шәһәр поликлиникаларында, Түбән Каманың перинаталь үзәкле балалар шәһәр хастаханәсендә, Түбән Кама үзәк күп профильле хастаханәсендә, Чистай үзәк район хастаханәсендә пациентларның кабул ителүгә язылу белән бәйле проблемалары булу ачыкланды.

Планлы төстә беренчел медико-санитар ярдәм күрсәткәндә диагностика инструменталь тикшеренүләр көтү вакытын сакламау фактлары бар. Мәсәлән, корсак куышлыгына ультратавышлы тикшеренү уздыруны сигез ай көтүче дә булган, тикшеренүне пациент Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына мөрәҗәгать иткәч кенә үткәргәннәр. («Әлмәт үзәк район хастаханәсе»). Хәтта Яр Чаллыда участок терапевты кабул иткәнне 7 көннән 14 көнгә кадәр, Казанда, Яшел Үзәндә 14 әр көн көткән очраклар бар.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы территориясендә сәламәтлек саклау учреждениеләрендә гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасында билгеләнгән планлы төстә күрсәтелә торган медицина ярдәме күрсәтү, диагностика инструменталь тикшеренүләр, табиб-белгечләр консультацияләре срокларын саклауны контрольгә алырга тәкъдим итә.

Гражданнарның медицина ярдәменә хокукын бозу мәсьәләләре буенча күп санлы мөрәҗәгатьләр уңаеннан Яшел Үзән муниципаль районында Вәкил әлеге территориядә халыкка медицина ярдәме күрсәтү эшен аерым өйрәнде.

«Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе» учреждениесе кадрларга кискен кытлык кичерә: табиблар белән тәэмин ителеш 58 процент тәшкил итә, эштән

китүчеләр күп. Күп кенә табиблар, амбулатор-поликлиника табибларына барулар саны бер кешегә республиканың уртача күрсәткеченнән ким булса да, икешәр табиблык участогында хезмәт күрсәтә.

Шуның белән бергә Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеш Стратегиясендә амбулатор ярдәме күрсәтүне 2020 елга кадәр 1,3 тапкыр арттыру планлаштырыла. Яшел Үзән муниципаль районында халыкның арту тенденциясен, халыкны амбулатор-поликлиника учреждениеләре белән тәэмин итү республиканың уртача күрсәткеченнән артып китүен исәпкә алып, республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгына, районнарның медицина оешмасы хакимиятенә сәламәтлек саклау учреждениеләренә табиб кадрларны җәлеп итүгә игътибарны юнәлтү зарур.

Татарстанда Казан, Яшел Үзән, Яр Чаллы шәһәрләренең кайбер медицина учреждениеләре базасында «Дустанә сырхауханә - Татарстан стандарты» проекты тормышка ашырыла, ул поликлиникаларның эш нәтиҗәлелеген күтәрүгә һәм пациентлар, персонал өчен уңайлы тирәлек тудыруга юнәлтелгән.

Әмма кадрлар белән тәэмин ителеш проблемасы әлеге проектны тормышка ашыручы поликлиникаларда да күзәтелә. Мәсәлән, Казан шәһәренең 18 нче сырхауханәсе баш табибы белдерүенчә, медицина учреждениесетабиблар белән 70, табиб-терапевтлар белән 87 процентка тәэмин ителгән.

Татарстан Республикасы халкының кан әйләнеше системасы авыруларыннан (2016 елның 11 ай йомгаклары буенча) үлү күрсәткече кимесә дә (100 мең кешегә - 596,3, 2015 елда 100 мең кешегә - 616,7) баш мие кан әйләнеше кискен авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтүдә шулай ук проблемалар бар.

Гражданнардан килгән шикаятьләр уңаеннан, Вәкил Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге дәвалау-профилактика учреждениеләрендә баш мие кан әйләнеше кискен авыруы белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү эшен өйрәнде.

Йөрәк-кан тамырлары үзәкләрен тикшерү барышында пациентларны

тиешле койкалар санынnан артып киткән очракларда стационарга урнаштыру очраклары ачыкланды.

Әйтик, тикшерү барышында «Яшел Үзән үзәк район хастаханәсе» учреждениесе базасындагы башлангыч йөрәк-кан тамырлары үзәгендә нормада каралган 30 койкага 50 пациент туры килүе ачыкланды.

Чаллы шәһәренең «5 нче шәһәр хастаханәсе» учреждениесе 1 нче неврология бүлегендә тикшерү барышында 45 койкага 48 пациент бар иде. Монда шунысын да әйтергә кирәк, элек (2010 елның ноябренә кадәр) әлеге учреждениедә 60 койка булган, соңрак Татарстан Республикасының «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» базасында яңа төбәкара йөрәк-кан тамырлары үзәге ачылганлыктан, койкалар 45 кә калдырылган.

Әлмәт (шәһәрдән башка), Азнакай, Лениногорск районнары районнары беркетелгән «Әлмәт үзәк район хастаханәсе»нә әлеге йөрәк-кан тамырлары авырулары белән килүчеләрнең саны арту күзәтелә. 2014 елда 554 кеше, 2015 елда — 666, 2016 елда — 763 кеше булган. Шуңа карамастан, «Әлмәт үзәк район хастаханәсе» башлангыч йөрәк-кан тамырлары үзәге буш урыннар булмау аркасында Азнакай муниципаль районыннан - 63, Лениногорск муниципаль районыннан 89 авыруга хезмәт күрсәтүдән баш тарткан.

Әлмәт үзәк район хастаханәсенең баш мие кан әйләнеше авыруы белән чирләүчеләр өчен неврология бүлегендә буш урыннар булмау аркасында, Азнакай, Лениногорск муниципаль районнары авырулары әлеге күрсәтелгән муниципаль районнардагы сәламәтлек саклау учреждениеләренең анестезиология һәм реанимация бүлекләренә китерелгән, алар хәлләре яхшырганчы стационар дәвалануда булган, монда аларның йөрәк-кан тамырлары үзәгендәге кебек җиһазларга ия булмавын әйтергә кирәк.

2017 елның I кварталына «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» базасында 30 койкага исәпләнгән йөрәк-кан тамырлары үзәген ачу планлаштырылган икәнен билгеләргә кирәк. Әмма алда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, бу гына аз.

Баш мие кан әйләнеше кискен авыруы белән авыручыларны тиешле һәм сыйфатлы медицина ярдәме белән тәэмин итү максатында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына сәламәтлек саклау учреждениеләре неврология бүлекләренең койка фондын киңәйтүне өйрәнү зарур.

Сәламәтлекне саклауга хокукны тормышка ашыруның мөһим критерие буларак медицина ярдәменең һәркемгә ачыклыгын төрле сәбәпләр, шул исәптән, җиһазның төзексезлеге киметә (шушы сәбәп белән җиһазларның тик торуы кайбер очракларда 34 көннән 102 көнгә кадәр тәшкил иткән). Андый фактлар Татарстан Республикасы Хисап палатасының бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануын тикшерү барышында Чаллы шәһәренең 5 нче шәһәр хастаханәсендә, Түбән Кама үзәк күп профильле хастаханәсендә, республика клиник хастаханәсендә, төбәкара клиника-диагностика үзәгендә, Чистай район хастаханәсендә ачыкланган. Ангиографлар төзек булмаганлыктан, кискен коронар синдромлы авырулар республика клиник хастаханәсенә китерелмичә, башка дәвалау учреждениеләренә җибәрелгән.

Кайбер җиһазларның техник характеристикалары дәвалау учреждениеләре таләпләренә тулысынча җавап бирми. Чаллы шәһәренең 5 нче шәһәр хастаханәсендә кирәкле җиһаз булмаганлыктан, пациентлар тикшеренүне учреждение мәйданын арендага алган «Авиценна», медицина клиник-диагностика үзәге» ширкәтендә уза. Моннан тыш, авыруларны, шул исәптән каты авыруларны да, компьютер томографиясе уздыру өчен теләсә нинди һава шартларында ишегалды аша 150 метр каталкада алып киләләр.

Соңгы елларда Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына гражданнардан җиһаз (маммограф, флюорография аппараты, томограф, денталь рентген) озак вакыт төзек булмау аркасында медицина ярдәме ала алмаулары турында шикаятьләр килә, ахыр чиктә гражданнар яшәү урыннарыннан ерак булган медицина учреждениеләренә (Урыссу, Яшел Үзән үзәк район хастаханәләре, Татарстан Республикасы «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе», Казан шәһәренең 8 нче, 21 нче

сырхауханәләре) мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Андый фактлар 2016 елда Казан шәһәренең 7 нче сырхауханәсендә, республика клиник онкология диспансерында, Бөгелмә үзәк район хастаханәсендә булды. Күп очракта әлеге проблемалар җиһазларның тузуы белән бәйле, аларны ремонтлау һәм алыштыру өчен шактый акча таләп ителә, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина учреждениеләренең проблеманы хәл итү өчен үзвакытында тиешле чаралар күрмәве очраклары да бар.

Гражданнарның хокукларын бозуга юл куймас өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына медицина учреждениеләрендә яңартуны таләп иткән җиһазлар исемлеген алырга, шулай ук диагностика җиһазы төзек булмау аркасында диагностика инструменталь тикшеренүләрне оператив хәл итү буенча чаралар күрергә кирәк.

## Инвалидларның хокукларын яклау

2016 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 1 декабрендә кабул ителгән 419 нчы «Инвалидлар хокуклары турында Конвенцияне ратификацияләү белән бәйле инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон көченә керде, ул инвалидлар өчен каршылыксыз тирәлекне этаплап булдыруда хокукый механизмнарны билгеле.

Конвенцияне гамәлгә ашыру буенча әле 2011-2012 елларда ук кабул ителгән практик чаралар "Уңайлы тирәлек" программасын кабул итү һәм тормышка ашыруда чагылыш тапты. Дәүләт программасы каршылыксыз тирәлек булдыру буенча киңрәк эшләр кабул итүне, инвалидларны тернәкләндерү һәм экспертиза системасын камилләштерүне, аларны укыту, эшкә урнаштыру, мәдәни хезмәт күрсәтүне камилләштерүне, спорт, туризм, иҗтимагый тормыш белән шөгыльләнүгә җәлеп итүне, шәхси мобильлекне тәэмин итүне, мәгълүмати-коммуникацион шартларны яхшыртуны күздә тота.

Куелган бурычларны уңышлы үтәү өчен дәүләт, федераль максатчан, төбәк программалары эшләнгән.

Татарстан Республикасында инвалидны тернәкләндерү яисә абилитацияләү шәхси программаларын тормышка ашыру, инвалид-баланы тернәкләндерү яки абилитацияләү шәхси программаларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының медико-социаль экспертиза федераль учреждениеләре белән бергәләп хезмәттәшлек итү буенча эшне оештыру максатларында, инвалидны тернәкләндерү яисә абилитацияләү шәхси программаларын тормышка ашыру, инвалид-баланы тернәкләндерү яки абилитацияләү шәхси программаларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының медико-социаль экспертиза федераль учреждениеләре белән бергәләп мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыру буенча ведомствоара эш төркеме төзү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 29 февралендә 310-р нчы карары кабул ителде. Күрсәтелгән органнарның мәгълүмати хезмәттәшлеген тормышка ашыру бурычы куелды.

Тулаем алганда инвалидларга карата дәүләт сәясәте Россия Федерациясе Конституциясендә каралган гражданлык, икътисадый, сәяси һәм башка хокукларны тормышка ашыруда инвалидларны башка гражданнар белән бертигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатын куя.

Шуның белән бергә, Вәкилнең элеккеге докладларында инвалидларның хокукларын тормышка ашыру белән бәйле проблемалар бер тапкыр гына билгеләнмәде. Узган ел гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караудан тыш, хәл ителмәгән мәсьәләләр барлыгын да күрсәтте, Вәкил проблемалы хәлләрне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге, «Татарстан Республикасы буенча медико-социаль экспертизасы баш бюросы» – дәүләт учреждениеләре катнашында коллегиаль карау механизмын файдаланды.

Гражданнарның зарлану сәбәпләренең берсе – санатор-курорт дәвалау путевкалары, тернәкләндерү техник чаралары белән тәэмин итмәү.

2016 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасында яшәүче инвалидларны тернәкләндерү техник чаралары, (протез-ортопедия әйберләрен эшләү һәм ремонтлауны да кертеп), санатор-курорт дәвалау пуетвкалары белән тәэмин итү буенча вәкаләтләр Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгыннан Россия Федерациясе Социаль иминият фондыныц Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесенә тапшырылды.

Россия Федерациясе Социаль иминият фонды мәгълүматы буенча, 2016 елда санатор-курорт дәвалау путевкалары дәүләт социаль ярдәме алучы гражданнарга 2013-2014 елларда тапшырылган гаризалар буенча бирелгән. 2015 елның 31 декабренә, «тернәкләндерү техник чаралары һәм путевкалар белән тәэмин итү турында» мәгълүмат базасын Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесенә тапшырган вакытка санатор-курорт дәвалау путевкаларына чират торучылар 45 362 кеше булган. 2017 елның гыйнварына бу сан 41 150 кеше.

Тернәкләндерү техник чаралары белән вакытында тәэмин итмәүләре турында Вәкилгә 2016 елның башына ук шикаятьләр килде. Мөрәҗәгатьләрне анализлау, тәэмин итмәү Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлегенә тапшырылган алучылар исемлегенец актуаль булмавына бәйле булуын күрсәтте.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге мәгълүматы буенча, 2016 елда төбәк бүлеге вәкилләре үткәрелә торган аукционнарның законга ярашлылыгын тикшерү буенча ТР буенча УФАС идарәсенең 30 утырышында катнашканнар, бу үз чиратында, төбәк бүлеге үткәрә торган аукционнар вакытларын өзүгә һәм

тоткарлауга китергән, монын нәтиҗәсе шул – контрактлар соңга калып төзелгән.

Тернәкләндерү техник чаралары белән тәэмин ителмәү аларга мохтаҗ инвалидларның баш авырту бәласе булып кала. Әйтик, 2016 елның III кварталында урын-җир әйберләре, подгузниклар белән тәэмин итүгә акча булмау халык арасында зур канәгатьсезлек тудырды.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлегендә үткән елда дәүләт контрактларында күрсәтелгән бәяләр буенча тернәкләндерү техник чаралары үзәкләрен оештыру тәкъдиме яңгыраган иде. Вәкил фикеренчә, әлеге тәкъдимне тормышка ашыру киеренкелек дәрәҗәсен киметә алыр иде, әмма монда шунысын да исәпкә алырга кирәк, мондый форматта барлык кирәкле тернәкләндерү техник чаралары да тәкъдим ителә алмый.

Инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләү шәхси планына ярашлы рәвештә, күрү буенча инвалидларны озатып йөрүче этләр белән тәэмин итү Татарстан өчен актуаль булып кала.

2016 елда Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге мәгълүматы буенча, аларны алуга 2016 елның гыйнварыннан бирле чиратта торган унөч кешенең өчесе генә тәэмин ителгән. Бер граждан озатып йөрүче эт алудан баш тарткан. Шулай итеп, 2017 ел башына 9 кеше тагын озатып йөрүче эт алуга чиратын көтәчәк. Шул ук вакытта инвалидларны озатып йөрүче этләр белән тәэмин итүгә дәүләт контрактлары шактый сирәк төзелә.

Узган еллар практикасы шуны күрсәтә, күрү буенча инвалидлар республика районнары прокурорлары аларның мәнфәгатен яклап судларга мөрәҗәгать иткәч кенә озатып йөрүче этләр белән тәэмин ителгән. Инвалидларның прокуратура органнарына, ә прокурорларның судларга мөрәҗәгать итү практикасы булмаганлыктан, Вәкил, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлегенә «Хезмәт Кызыл байрагы орденлы Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте»

Россиякүләм инвалидлар иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге фикерен исәпкә алып, күрү буенча инвалидларны озатып йөрүче этләр белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатка ярашлы булыр иде дип саный.

Финанс белән тәэмин ителеш проблемаларыннан тыш, тернәкләндерү техник чараларын кайтартуны оештыруда кыенлыклар бар.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге мәгълүматлары буенча, тернәкләндерү техник чараларын тапшыру пунктларына урнаштыру яки автомобильне адресы буенча илтү аларны алу урыннарын төгәл белгәннән соң гына тормышка ашырыла. Шуның белән бергә, шикаятьләрнең кайбер өлеше тернәкләндерү техник чараларын тиешле җиргә илтеп җиткермәүгә кагыла.

Вәкил адресына кирәкле тернәкләндерү техник чараларын нәкъ менә өйләренә китерергә мохтаҗ өлкән яшьтәге инвалидлардан мөрәҗәгатьләр керә. Ә тәэминатчылар гражданның өйдә булмавына сылтый, ә инвалидлар киресен раслый.

Вәкил монда халык белән адреслы эшләү кирәк дип саный, шулай ук гражданнарны тернәкләндерү техник чаралары белән тәэмин итү эшен камилләштерү максатында тәэминатчыларның алучылар белән бергә эшләү һәм элемтә тәртибен, ничек китертү ысулларын күздә тоткан җентекле методиканы эшләү зарур.

Инвалидларның соңиаль, инҗенерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларында йөрү хокукларын бозу очраклары бар. Кайвакыт мәгънәсез эшләр дә була.

Әйтик, «Франт» сәүдә үзәге янындагы физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен каралган тукталыш урыннарына кар өеп куйганнар. Әлеге участокны Вәкил катнашканнан соң гына чистарттылар.

Инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларында каршылыксыз йөрүен тәэмин итү максатларында, Вәкил «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыяте»нең Татарстан Республикасы инвалидлар оешмасы, Татарстан Республикасы Хезмәт,

мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Казан шәһәре бүлеге, «Гомумроссия халык фронты»нын Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге белән берлектә һәм җәмәгать ярдәмчеләре белән Казан шәһәренен халыкка хезмәт күрсәтүче кайбер объектлары территорияләрендә физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен тукталыш урыннары оештыру мәсьәләләре буенча урынга чыгып тикшерүләр үткәрде.

Тикшерүләр Казан шәһәрендә хокук бозулар фактларын күрсәтте. Кайбер объектларда ГОСТ Р 50597-93 таләпләрен бозып билгеләнгән урын начар күренә яки билгеләнмәгән иде («Максидом», МЕТРО, «ЦУМ», «Планета Фитнес»). 1995 елнын 24 ноябрендә дөнья күргән 181 нче федераль законның положениеләрен бозып, инвалидларнын махсус автотранспорт чараларына туктау өчен урыннарның 10 процентган кимрәк бирелүе очраклары да ачыкланды («Ак Барс» көрәш сарае, су спорты төрләре сарае, «Планета Фитнес», «АкваАрена»).

Мондый тикшерүләрне вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре Россия Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең муниципаль берәмлекләре бүлекләре, районнардагы социаль яклау органнары белән бергә үткәрделәр.

Мәсәлән, Лениногорск шәһәрендәге эш төркеме «Эссен» сәүдә үзәге «Оптовик» җәмгыяте парковкасында 140 туктау урыны булып, шунын җидесе инвалидларга бүленеп тә, дүртесендә җәйге сату ноктасы урнашуын ачыклады.

Яр Чаллы шәһәре эш төркеме «Автозаводский» сәүдә үзәге, «3 нче шәһәр сырхауханәсе», «Мастеровые рус драма театры», «Тулпар» сәүдә үзәге, «2 нче балалар шәһәр сырхауханәсе» сәламәтлек саклау учреждениесе янында «Инвалидлар» дигән язу булмавын ачыклады.

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең транспорт буенча комитеты Россия Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Казан шәһәре бүлегенә инвалидларга туктау рөхсәт ителгән, шулай ук инвалидларны һәм инвалид балаларны йөртүче затлар реестрын тапшырды (күрсәтелгән реестрда 1700 дән артык автомобиль

теркәлгән инде). Әлеге чара инвалидларны дөрес туктамаган өчен штрафка тарту очракларын бетерергә мөмкинлек бирде.

Вәкил фикеренчә, алга таба хуҗалары инвалидлар булган автомобильләрнең бердәм республика электрон реестрын төзү дә максатка ярашлы булыр иде.

Медицина оешмалары күзәтүенә урнаштырылган хокукларын якларга сәләтсез гражданнар хокукларын саклау белән бәйле хәлләрне анализлаганда, Вәкил әлеге төр гражданнарның милеккә хокукларын саклау кирәклегенә игътибарны юнәлтә.

Узган елда Вәкилнең җаваплы кешеләре академик В.М.Бехтерев исемендәге республика психиатрия хастаханәсен тикшерде. Анда учреждениенең медицина оешмасы күзәтүенә урнаштырылган, хокукларын яклауга сәләтсез гражданнарга карата опекун вазифаларын үтәве, аларның милеккә хокукларын, шул исәптән торак милекчеләре яки торактан файдаланып торучылар булган хокукларын яклауга сәләтсез гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм саклау мәсьәләләре тикшерелде.

Хокукларын яклауга сәләтсез гражданнарның шәхси эшләрен сайлап өйрәнү нәтиҗәләре шуны күрсәтте, учреждение күчемсез милек турында мәгълүмат җыюны тормышка ашыра, хезмәткәрләр Казан шәһәрендә урнашкан торак биналарны даими тикшереп тора. Моннан тыш, алар карамагындагы авыруларның торакка түләү буенча бурычлары бар икән, аларны түләү, коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр белән килешмәгән очракта идарәче оешмалар адресына кабат исәпләү турында таләп җибәрелә. Әлеге фактлар учреждениенең тиешле эш үткәрүе турында дәлилли.

Шуның белән бергә, Вәкил фикеренчә, Казан шәһәреннән читтә яшәүче авыруларның торак йортларын саклау буенча эш башкарганда зур активлык таләп ителә.

Әйтик, учреждение карамагындагы берәүнең шәхси эшендә «Академик В.М.Бехтерев исемендәге республика психиатрия хастаханәсе» сәламәтлек саклау учреждениесе хакимиятенең торак йортны саклауны тәэмин итү буенча

тиешле чаралар күрмәве хакында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елда язган хаты саклана. Хокукларын яклауга сәләтсез кешенең бергә яшәгән энисе 2009 елда вафат булган. Үз чиратында учреждениедән җирле үзидарә органына алар карамагындагы затларның торагын һәм милкен саклау опека һәм попечительлек органына йөкләнә дигән җавап юлланган.

Әлеге мисал йөкләмәләрне асылда хәл итмичә берсеннән берсенә аударырга тырышу турында дәлилли.

Мондый хәлләрнең кабатлануына юл куймау өчен Вәкил учреждение алар карамагындагы затларнын торак йортлары торышы турында объектив мәгълүматлар ала алмаган очракта, РФ Гражданнар кодексының 38 маддәсенә ярашлы рәвештә идарәче билгеләү һәм алар белән күчемсез милек белән оператив идарә итү турында килешү төзү мәсьәләсе белән опека һәм попечительлек органнарына мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә. Әлеге мәсьәләне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы җирле үзидарә органнары белән бергәләп хәл итәргә тиеш.

## Миграция мөнәсәбәтләрендә кеше хокукларын яклау

Узган 2016 ел 2015 елга кадәрге Россия Федерациясе дәүләт миграция сәясәте Концепциясен тормышка ашыруның икенче этабы башлану булды. Анда дәүләт миграция сәясәте төп юнәлешләре кысаларында программаларны тормышка ашыру, хокукый практиканы тулыландыру һәм анализлау, мәгълүмати технологияләрне куллануны кинәйтү, норматив хокукый актларны әзерләү, вакытлыча хезмәт эшчәнлеге турында килешүләр төзүне үз эченә алган халыкара хезмәттәшлек, Россиядә эшләү өчен гражданнарны сайлау алу, ике якның да медицина документларын тану, вакытлыча яшәүгә, яшәп торуга

рөхсәт биргән институтларны камилләштерүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул итү, дәүләт контролен камилләштерү һәм башкалар каралган.

Татарстан Республикасы өчен күрсәтелгән бурычларны хәл итү актуальлеге шуның белән нигезләнгән, 2016 елда 250 506 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган зат миграция исәбенә куелган (бу 2015 ел белән чагыштырганда 6,7 % ка күбрәк).

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасында чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукый хәле билгеләнмәгән килеш калу хәле саклана.

2016 елда Россия Федерациясеннән административ чыгарып җибәрү турында 1477 карар кабул ителгән, (шулардан 845 кеше чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә тотылган) һәм депортация турында 30 карар чыгарылган.

Депортация турында карарларның гомуми саныннан унбере гражданлыгы булмаган затларга кагыла. Депортация турында карар һәр очракта да чыгарыла торган кеше үз иленә кайта дигәнне аңлатмый. 2016 елда реадмиссия турында 3 кенә карар кабул ителгән, ул дәүләтнең мәҗбүри кайтартылган гражданнарны, шул исәптән, аның территориясеннән чыккан затларны үзенә кабул итүгә ризалыгын аңлата. Калган очракларда гражданның юлы билгесез кала. Кагыйдә буларак, бу кешеләр Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасындагы гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгенә китереләләр, алар озак вакыт шунда тотылалар. Бу уңайдан шунысын да әйтергә кирәк, гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә озак вакытлар тоту кеше хокуклары буенча Европа судында карауга да китерде.

Күрсәтелгән хәлләрне исәпкә алып, Вәкил федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе, суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе, Татарстан Республикасы Югары суды, «Юридик клиника» мигрантларга һәм Татарстан Республикасының социаль яктан якланмаган башка катлауларына хокукый ярдәм үзәге» төбәк иҗтимагый

үзәге, милли-мәдәни автономияләр вәкилләре белән очрашты. Аның нәтиҗәләре буенча документларда хаталар булганда мигрантлар эшләрен карау срокларына, җинаять эше һәм башка мәсьәләләр буенча эш алып барганда махсус учреждениеләр биналарын гражданнарны тоту өчен куллану фактларын булдырмауга кагылышлы карарлар кабул ителде.

Кызыксынучан зат сыйфатында Вәкил берничә тапкыр Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасындагы гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә озак вакытлар тотылган гражданлыгы булмаган затларны чыгарып җибәрү перспективасы булмаганлыктан, Россия Федерациясе чикләреннән мәжбүри чыгарып жибәрү буенча үтәү карарларын туктату турында суд приставлары-башкаручылары гаризалары буенча суд утырышларында катнашты. Суд практикасы шуннан гыйбарәт: суд приставы-башкаручысы гаризасы ике шарт: чит ил гражданы килгән дәүләттә гражданлыгын югалту факты ачыкланганда, шулай ук аның якын туганнарының Россия Федерациясе гражданлыгы булганда канәгатьләндерелә.

Барлыкка килгән суд практикасын исәпкә алып, Вәкил суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә Эчке эшләр министрлыгынын Татарстан Республикасындагы гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә озак вакытлар тотылган гражданлыгы булмаган затларны чит ил гражданы килгән дәүләттә гражданлыгын югалту турында һәм аның якын туганнарының Россия Федерациясе гражданлыгы булуы турында белешмәләр булганда, Россия Федерациясе чикләреннәнмәҗбүри чыгарып җибәрү буенча үтәү карарларын туктату турында суд приставлары-башкаручылары гаризаларын бирү практикасын дәвам итәргә мөмкин дип саный.

Тулаем суд практикасы, чит ил гражданнарының хокукларын бозу Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасындагы гражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә тоту срокларын бозу, килгән урынында теркәүне исәпкә алуны озынайтканда законсыз кире

кагу, яшәп торуга рөхсәт бирүне законсыз кире кагу, патентны законсыз юкка чыгару һәм башка очраклар белән бәйле булырга мөмкинлеген күрсәтә.

Вәкил ВИЧ-инфекцияле чит ил гражданнарының Россия Федерациясе территориясендә яшәмәве (булмавы) хәерлерәк булу турында карарны юкка чыгару буенча хокукларны тормышка ашыруда кыенлыклар булуга игътибарны юнәлтә.

Вәкил адресына аның хатыны һәм кызының Россия Федерациясендә яшәмәве хәерлерәк булу турында карарны юкка чыгаруда булышлык итүне сорап, граждан П. мөрәҗәгать итте. Гариза бирүченең хатынына һәм кызына медицина тикшеренүе уздыру нәтиҗәсендә ВИЧ-инфекция булу ачыкланган, нәтиҗәдә 2013 елда Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе әзерләгән карар проекты нигезендә Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт аның Россия Федерациясендә яшәмәве хәерлерәк булу турында карар кабул итә.

Шушы уңайдан 2016 елның мартында 1995 елның 30 мартында дөнья күргән «Россия Федерациясендә ВИЧ-инфекция таратмау турында» 38 нче федераль законның 11 нче маддәсенә үзгәрешләр кертелде, шулай итеп әлеге маддәдә каралган ВИЧ-инфекция булу факты илдә яшәмәү хәерлерәк булу турында карар кабул итү өчен нигез булудан туктады, ВИЧ-инфекцияле чит ил гражданнары югарыда күрсәтелгән федераль закон положениеләрен бозмаган очракта, суд тәртибендә Россиядә яшәмәү хәерлерәк булу турындагы карарны кире кагу хокукын алдылар.

Ләкин, Россия Федерациясендә яшәмәү хәерлерәк булу турында карарны кире кагуны йөкләгән гариза Россия Федерациясендә административ суд производствосы турында Кодекс кагыйдәләре буенча карала, чит ил гражданына югары юридик белемле вәкил табарга, чит илдә килеш, Россия Федерациясе территориясенә үзе керә алмаганлыктан, судта үзен якласыннар өчен ышаныч кәгазе эшләтергә кирәк. Граждан П. очрагында карар уңай булды, аның гаиләсе безнең ил территориясенә кайта ала, ләкин Россия Федерациясе

территориясендә яшәмәве хәерлерәк булу турындагы карарны юкка чыгару өчен судка гариза бирүгә әзерлек процедуралары берничә айга сузылды. Шушы вакыт эчендә граждан гаиләсеннән аерым яшәде.

Мигрантлар хокукларын яклау белән шөгыльләнүче оешмаларга мондый хәлләр кабатланган очракта эш гамәлләрен аңлату һәм киләчәктә мондый очракларда хокукый ярдәм күрсәтү өчен әлеге тема буенча «кайнар элемтә» үткәрү кызык булыр дип уйлыйбыз.

## Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затларның хокукларын яклау

Вәкил һәм аның Аппараты тарафыннан мәҗбүри тоту урыннарында булган һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга карата кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга булышлык итү буенча даими эш дәвам итә.

Хөкем ителгәннәрнең тәртибен бәяләү буенча комиссия составында эшләгәндә, Вәкил «социаль лифтлар» буенча комиссияләр тәкъдим иткән хөкем ителгәннәргә уңай характеристика саны белән шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителү турында юлламаларны канәгатьләндерү турында судлар карарлары саны арасында сизелерлек аерма булуын билгеләде. Шушы уңайдан Вәкил башлангычы белән Татарстан Республикасы Югары судында суд системасы, прокуратура органнары, Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашында «Азат итү турында хөкем ителгәннәрнең юлламаларын карау практикасы» дигән темага «түгәрәк өстәл» дә үткәрелде.

Чара йомгаклары буенча, хөкем ителгәннәрне җәза үтәүдән шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итүне куллану практикасын бер итү максатында, резолюция кабул ителде, аңа ярашлы рәвештә вакытыннан алда азат ителүгә юллама бирелгән хөкем ителүче шәхесенә бәя бирү буенча тәкъдимнәр эшләнде, болар аның иректән мәхрүм итү урыннарында төзәлүен карауны,

төзәтү учреждениеләре хакимиятләренең хөкем ителгәннәргә материалларны судка үзвакытында җибәрүен һәм башкаларны күздә тота. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә җәза үтәүдән шартлы рәвештә вакытыннан алда азат итү куллану турында суд чыгарган карарларны либераллаштыру тенденциясе күзәтелде.

Үз чиратында хөкем ителгәннәрне җәза үтәүдән каты авыру аркасында азат итү проблемасы борчу тудыра.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматлары буенча, республика судларына 2016 елда хөкем ителгәннәрне җәза үтәүдән каты авыру аркасында азат итү турында 24 материал җибәрелгән, 11 тоткын азат ителгән. Каты авыру аркасында җәза үтәтүдән азат итү турында материаллар җибәрелгән хөкем ителгәннәрнен барысы да азат ителмәү факты игътибарны җәлеп итә, бер кеше үлгән дә. 2016 елда каты авыру аркасында җәза үтәтүдән азат итү турында суд карар чыгарганчыга кадәр 7 тоткын үлеп киткән.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә хөкем ителгәннәрне каты авыру аркасында җәза үтәтүдән азат итү турында судка вакытында материаллар әзерләү һәм җибәрү кирәклегенә игътибар итү, эшләрне вакытында карамау очракларында андый фактлар турында Татарстан Республикасы Югары суды җитәкчелегенә хәбәр итү максатка ярашлы булыр иде дип саный.

2016 елда Вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән берлектә, хөкем ителгәннәргә «Хокукый ярдәм көне» кысаларында җәза үтәү мәсьәләләре буенча төзәтү учреждениеләрендә хөкем ителгәннәрне шәхси кабул итү буенча эш дәвам итте. Әлеге чара кысаларында иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче затлар үзләрен кызыксындырган сорауларга кайбер дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Адвокат палатасы, Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы,

иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән аңлатмалар алу мөмкинлегенә ия булдылар.

Аңлату эшләреннән тыш, Вәкил төзәтү учреждениеләре кибетләрендә беренчел ихтыяҗ товарлары булмау, хөкем ителгәннәрнең аерым категорияләренә өстәмә туклану өчен (стационарда булучылар, ВИЧ-инфекцияле авырулар, инвалидлар һәм башкалар өчен) кайбер төзәтү учреждениеләрендә сөт һәм эремчек юклыкка, шулай ук хөкем ителүчеләр тотылучы төзәтү учреждениеләренең кайбер биналары тузган булуга игътибарны юнәлтте.

Шушы уңайдан Вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчелегенә күрсәтелгән проблемаларны хәл итү юлларын табу тәкъдиме белән хат җибәрде.

Суд карарлары, төзәтү колонияләрендә һәм тикшерү изоляторларындагы тоту шартларына кагылышлы шикаятьләрдән тыш, иректән мәхрүм итү урыннарында булучылардан дәүләт яки муниципаль фондтан торак алуга хокукны тормышка ашыруга, социаль яклау чаралар алуга, эшкә урнашуга һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы мөрәҗәгатьләр дә җитәрлек.

Вәкил адресына ятим балалардан, караучысыз калган, иректән мәхрүм итү урыннарында булган балалардан аларны торак белән тәэмин итүгә кагылышлы мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр килә.

Гамәлдәге законнар балигъ булмаган яшьтә ятим балалар дип танылган һәм торак шартларын яхшыртучысыйфатында билгеләнгән тәртиптә исәпкә куелган затларны 23 яшькә җиткәнче махсус торак фондыннан торак белән тәэмин итүгә хокук бирә.

Килеп туган хәлне анализлау шуны күрсәтә, ятим бала төзәтү учреждениесенә килү белән учреждениенең җитәкчеләре җирле үзидарә органнарына аның торагына кагылышлы сорау хаты (запрос) җибәрә. Мондый хат бер генә тапкыр җибәрелә һәм хөкем ителүчене азат итүгә алты ай кала торак белән тәэмин итү турындагы мәгълүмат кабат тикшерелә.

Шуның белән бергә, торак шартлары начараю хөкем ителүченең торак белән тәэмин ителүе турында җавап алганнан соң алар җәза үтәгән вакытта булырга мөмкин. Әлеге хәлләр турында хөкем ителүче үзе һәм төзәтү учреждениесе хезмәткәрләре белмәскә дә мөмкин. Шулай итеп, 23 яше тулгач азат ителгәндә аның тиешле гариза бирмәгән очракта махсуслашкан торак фондыннан торак алуга хокукын югалтуы да ихтимал. Моннан тыш, практика төзәтү учреждениеләре житәкчеләренең иректән мәхрүм итү урыннарында булган ятим балаларның торак белән тәэмин ителүен сораган хаты озак вакытка җавапсыз калырга мөмкинлеген дә күрсәтә. Шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарында булган ятим балалар гаризасы, аны исәпкә кую турындагы мәгълүматлар вәкиллек органында (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы) булмаска да мөмкин, чөнки мондый мөрәҗәгатьләрне карау белән элек җирле үзидарә органнары шөгыльләнде.

Иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче ятим балалар исәбенә керүче гражданнарның, аларны торак шартларын яхшыртуда мохтаҗ булучы сыйфатында исәпкә кую гаризасын үзвакытында тапшырмау очракларын һәм бәхәсле хәлләрне булдырмау максатыннан, андый гражданнар яшәп торган торакта аларга 23 яшь тулганга кадәр яшәү-яшәмәү мөмкинлекләре турында хәлләрне ачыклау буенча даими эш үткәрү максатка ярашлы булыр иде. Мондый тәртипне эшләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенен Татарстан Республикасындагы идарәсе һәм җирле үзидарә органнары бергәләп хезмәттәшлек иткәндә мөмкин.

Вәкилгә алга таба җәзаны үтәү өчен бер төзәтү учреждениесеннән икенчесенә күчерүгә булышлык итүне сораган мөрәҗәгатьләр керә.

Практика шуны күрсәтә, мондый гаризаларны канәгатьләндерүне Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте дә (Россия Федерациясенең башка субъектындагы төзәтү учреждениесенә күчергәндә), Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе дә (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төзәтү учреждениесенә күчергәндә)

хөкем ителүче авырган яки аның шәхси иминлеген тәэмин итү очракларында гына тормышка ашыра.

Россия Федерациясе Җинаять-үтәү кодексы положениеләре һәм Россия Федерациясе Конституция суды хокукый позициясе буенча, 2015 елның 16 июлендә дөнья күргән 1611-О нчы карарында билгеләнгән, хөкем ителүчене бер төзәтү учреждениесеннән икенчесенә алга таба җәзаларны үтәү өчен күчерүдә искәрмәле хәлләр исемлеге ахыргы була алмый.

Шуның белән бергә, башка искәрмәле хәлләр киң таралыш алмаган. Моннан тыш, 2016 елның декабрендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Москалькова рәислегендә узган Кеше хокуклары буенча Россия вәкаләтле вәкилләре Координацион советы утырышында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте вәкилләре хөкем ителгәннәрне күчерү буенча законда турыдан-туры күрсәтелгән искәрмәле хәлләрдән тыш, башкасын әйтә алмадылар.

Шунысын да билгеләргәә кирәк, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2010 елның 14 октябрендә дөнья күргән 1772-р нче карары белән расланган Россия Федерациясендә 2020 елга кадәр җинаять-үтәү системасын үстерү Концепциясенә ярашлы рәвештә, җинаять-үтәү сәясәтен камилләштерү кысаларында хөкем ителгәннәрнең социаль файдалы элемтәләрен саклау өчен, туганнары өчен җәзаларны үтәтү урыннары якын булсын өчен, ил территориясендә җәзаларны үтәтү урыннарын урнаштыруны оптимальләштерү күздә тотыла. Иректән мәхрүм итү урыннарында социаль һәм психологик эшнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, иректән мәхрүм итү урыннарында булган гражданнар белән аларның якыннары арасындагы социаль файдалы элемтәләрне өзүгә юл куярга ярамый.

Күрсәтелгән бурыч уңаеннан Вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчелегенә иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче затларның башка төзәтү учреждениесенә күчерү турындагы гаризасын хөкем ителүченең якын туганнары белән күрешү хокукларын исәпкә алып карарга тәкъдим итә. Вәкил фикеренчә, күчерү

турындагы гаризаларны караганда хөкем ителүченең якын туганнарынын ерак араларга барырга мөмкинлекләре чикләнү кебек хәл дә игътибарга алынырга мөмкин.

## Йомгак

Докладта күрсәтелгән кеше хокукы яклау проблемаларыннан чыгып, Вәкил түбәндәге нәтиҗәләргә туктала.

Республикада хезмәт хакларын түләмәү очракларын кисәтү буенча системалы эш алып барыла. Эш бирүче намуссызларга каратакомплекслы чаралар кулланыла, шул исәптән җинаять эше дә кузгатылырга мөмкин. Үз чиратында, хезмәт хакын өлешчә яки тулысынча түләмәү факты буенча эш бирүчегә җинаять эше ачылган очракта, өстенлекле максат гаепләү карары чыгару түгел, ә бәлки җыелган бурычларны каплау буенча чаралар булырга тиеш.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләтнең максатчан сәясәте булуга карамастан, гражданнарның эш эзләве белән бәйле кагыйдә бозулар күзәтелә. Шуңа бәйле рәвештә, эш эзләүче гражданнарның эшлеклелек сыйфатлар белән бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшкә алынмаганнарның хезмәткә хокукын яклау эше көчәйтелергә тиеш.

Торак төзелеше кызу темплар белән барганда, гражданнарнын торак хокукын саклауда проблемалы хәлләр чыгып тора.

Республикада магистраль торба үткәргечләрнең саклык зонасы чигенә урнашкан торак йортларны сүтү буенча бик җитди проблема килеп туды. Шуңа бәйле рәвештә, газ белән тәэмин итү системасы объектларының икътисади куркынычсызлыгы үзенчәлеген исәпкә алмыйча торак төзелеше өчен җир участокларын бүлеп бирүгә юл куймау буенча тизарада чаралар күрелергә тиеш.

Яшәү өчен яраксыз биналарда яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту белән бәйле хәл ителмәгән мәсьәләләр бар.

Торак шартларын ипотека кредиты юлы белән яхшырту механизмы үсешенә бәйле рәвештә, кереме аз дип саналмаган, әмма булачак квартир өчен түләүләре теге яки бу сәбәп аркасында гаиләнең тулаем кеременнән шактый зур

өлешен тәшкил иткән социаль ипотекада катнашучы гражданнарның торак хокукын тәэмин итүдә өстәмә чаралар таләп ителә.

Төзелеш кимчелекләре булган йортларда яшәүче гражданнарның хокукын яклау буенча өстәмә чаралар кабул итәргә кирәк.

Казан шәһәрендә торак биналарын гражданнар милкенә тапшыру (хосусыйлаштыру) буенча килешүләр төзегәндә элеккеге фатирда балигъ булмаган бала исәптән төшерелгән булса, килешү төзегәндә авырлыклар килеп чыга.

Гражданнарның тулы күләмдә квалификацияле медицина ярдәме күрсәтүгә хокукын яклау максатында, стационарда дәваланучыдан, медицина учреждениеләрендә булмау сәбәпле, дару сатып алдыру фактларын булдырмау буенча контрольне көчәйтергә. Республикада кан тамырлары авырулары үзәкләрендә койка фондын киңәйтү белән бәйле хәл дә игътибар белән тикшерүне таләп итә.

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт программасы кысаларында амбулатор-поликлиника ярдәме күрсәтүче оештыручы медицина оешмаларында белгечләргә язылганда проблемалар бар. Татарстанлыларга медицина ярдәме алуда авырлыклар теге яки бу сәбәп аркасында медицина техникасының тик торуы белән дә бәйле булырга мөмкин.

Инвалидлар җәмгыятьтә башка гражданнар белән бертигез тулы канлы тормыш белән яши алмаса, социаль сәясәтне нәтиҗәле дип санап булмый. Инвалидларга тигез мөмкинлекләр тудыру дигәндә социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына тоткарлыксыз килергә мөмкинлек тудыручы комплексы чаралар күз алдында тотыла.

Инвалидларны тернәкләндерү техник чаралары белән тәэмин итүдә дә кыенлыклар кала бирә. Медицина оешмалары күзәтүе астына алынган хокукларын яклауга сәләтсез гражданнарның милеккә хокукын саклау буенча да эшне активлаштыру максатка ярашлы.

Пенитенциар система учреждениеләрендә кеше хокукларын тәэмин итү һәм саклау, иректән мәхрүм итү урыннарында утырып чыккан затларны тормышка яраклаштыру да актуаль проблемаларның берсе булып кала бирә.

Кеше хокукына карата хөрмәт гражданлык җәмгыяте үсеше белән өзлексез бәйле. Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар ярдәме дә мөһим.

Югарыда күрсәтелгәннәрне исәпкә алып, кеше һәм гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм яклау максатыннан, Вәкил, дәүләт оешмаларына, җирле үзидарә органнарына, вазифадагы затларга түбәндәге чараларны тәкъдим итә:

1. Гражданнарның сайлау хокукын тормышка ашыру максатыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенәтавыш бирү өчен бүлмәләрнең, лифт яки халыкнын авырлык белән йөрүче төркемен күтәрү өчен башка корылмалар булмаганда, беренче каттан да югары булуына юл куйдырмаска.

2. Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыятен алга таба да үстерү, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү, иҗтимагый оешмаларның кеше һәм гражданнарның ирекләрен һәм хокукларын яклау эшендә катнашуы максатында:

2.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек, социаль яклау министрлыгына халыкка социаль хезмәт күрсәтүдә иҗтимагый оешмалар катнашуы буенча Пермь крае тәҗрибәсен өйрәнергә һәм аны куллану мөмкинлеген карарга.

2.2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма хезмәтләре өчен даими рәвештә квалификацияне күтәрү курслары, өйрәтү курсларын оештыру мөмкинлеген карарга.

2.3. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгына Татарстан Республикасында социаль мөһим проектларны

тормышка ашыру турында республика массакүләм мәгълүмат чараларында даими мәгълүмат материаллары урнаштырып, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга мәгълүмати яктан ярдәм итәргә.

3. Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын тормышка ашыру максатында:

3.1. Хезмәт законнарын контрольдә тотучы дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына (яшәү дәрәҗәсен күтәрү һәм легальләштерү буенча ведомствоара комиссия эше кысаларында), Россия Федерациясе Җинаять Кодексының 145.1 маддәсе буенчаҗитәкчеләренә карата җинаять эше кузгатылган, хезмәт хакы буенча бурычлары булган оешмалардан бурычларны каплату өчен мөмкин булган барлык чараларны кулланырга.

3.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау органнарына эш эзләүчеләрнең эшлекле сыйфатлары белән бәйле булмаган сәбәпләр белән эшкә алудан баш тарту очраклары турында прокуратурага хәбәр итү буенча эшне активлаштырырга.

4. Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру максатында:

4.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына торакны сатып алу хокукы өчен җитәрлек өстәмә финанс ресурсы булган очракта алга таба, милекне сатып алу хокукын саклап, вакыты чикләнмәгән найм шартларында торакны социаль ипотека программасында катнашучыга бирү мөмкинлегенең нигезләре исемлеген киңәйтү мөмкинлекләре турындагы мәсьәләне карарга.

4.2. «Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмага социаль ипотека программасы буенча объект (торак йорт) төзүгә подряд килешүләрендә социаль ипотека программасы буенча элек төзелгән йортларга гарантияле хезмәт күрсәтү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре бар икән, андый подряд оешмаларын төзелешкә кертмәү максаты белән төзелешкә субподрядчыларны бары тик төзүче-инвестор белән килешеп җәлеп итү турында пункт кертергә тәкъдим итәргә кирәк.

4.3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына яшәүчеләрнең яртысы күчерелгән, шул исәптән Казан шәһәренең тузган торак фондын һәм тузган торак кварталларын бетерү программасы кысаларында, РФ Хөкүмәтенен 2006 елның 28 нче гыйнварында дөнья күргән 47 нче карары белән расланган торак бинасын һәм күп квартирлы йортны яшәүгә яраксыз дип тану турындагы таләпләргә туры килгән тузган торак йортларнын ярашлылыгын бәяләү буенча эшне оештыру мәсьәләсен карарга.

4.4. Җирле үзидарә органнарына газ белән тәэмин итү системасы объектларынын сәнагать куркынычсызлыгы үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча, торак төзелеше өчен җир участокларын бүлү кебек хәлләргә юл куймау максатыннан, файдаланучы оешмалары материаллары буенча магистраль үткәргечләрнең урыны турында мәгълүматка төгәллек кертү буенча чаралар күрергә.

4.5. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2012 елның 28 нче июнендә дөнья күргән 4310нчы карары белән расланган гражданнарга торак бинаны хосусыйлаштыруга рөхсәт итү килешүен рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче административ регламентка өстәмәләр кертү турында мәсьәләне карарга, аерым алганда,бу Казан шәһәре муниципаль торак фондынын торак бинасын хосусый милек итеп рәсмиләштергәндә, элек торак бинадан балигъ булмаган бала теркәүдән төшерелгән булса, опека һәм попечительләр органыннан рөхсәт документын күрсәтүгә кагыла.

5. Гражданнарнын сәламәтлеген саклауга һәм медицина ярдәме алуга хокукын яклау максатында:

5.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

стационарда дәваланучы авыруларнын медицина учреждениесендә булмавына сәбәп итеп, даруларны үзләренә сатып алу фактларын булдырмауга контрольне көчәйтергә;

сәламәтлек саклау учреждениеләренең неврология бүлекләрендә койка фондын арттыру турында мәсьәләне карарга;

йөрәк-кан тамырлары авырулары үзәкләрен кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

тик тотмау һәм вакытында ремонт ясау максатыннан, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина техникасын файдалануга контрольне көчәйтергә;

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга бушлай медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантиясе программасы кысаларында амбулатор-поликлиника ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында белгечләргә вакытында язылуны оештыруга юнәлтелгән өстәмә чаралар күрергә.

6. Инвалидларның хокукларын яклау максатыннан:

6.1. Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлегенә:

тернәкләндерү техник чараларын китереп бирүчеләрнең, аерым алганда, алучының (инвалидның) яшәү урынына үз вакытында китереп бирүенә контрольне көчәйтү вариантларын карарга;

алына торган тернәкләндерү техник чараларының сыйфатына контрольне көчәйтергә;

күрү буенча инвалидларны аларның реабилитация яки абилитация шәхси планнарына ярашлы рәвештә озатып йөрүче этләр белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

6.2. Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча ЮХИДИ идарәсенә җирле үзидарә органнары белән берлектә инвалидларның транспорт чараларының бердәм республика электрон реестрын булдыру турында мәсьәләне карарга.

6.3.Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең опека һәм попечительләр органнары белән берлектә, милек, медицина оешмасы эшчәнлек алып барган территориядән читтә урнашкан очракта, авыруның милке белән туганнары идарә итү турында килешү төзү практикасын куллану юлын да кертеп, хокукларын яклауга сәләтсез дип табылучы һәм медицина учреждениесенә

урнаштырылучы гражданнар торакларын саклау буенча чараларны көчәйтү мәсьәләсен карарга;

7. Мигрантлар хокукларын яклау максатында Суд приставлары федераль хезмәтенен Татарстан Республикасындагы идарәсенәгражданнарны һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту үзәгендә озак вакытлар тотылган, гражданлыгы булмаган затларны чит ил гражданы килгән дәүләттә гражданлыгын югалту турында һәм аның якын туганнарының Россия Федерациясе гражданлыгы булуы турында белешмәләр булганда, Россия Федерациясе чикләреннән мәҗбүри чыгарып җибәрү буенча үтәү карарларын туктату турында суд приставлары-башкаручылары гаризаларын бирү практикасын йөкләргә.

8. Мәҗбүри тоту урыннарында булучы затларнын хокукларын яклау максатында:

8.1. Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенеңТатарстан Республикасындагы идарәсенә:

Хөкем ителүченең каты авыруы белән бәйле җәзаны үтәүдән азат ителү турында материалларны судка әзерләү һәм үз вакытында җибәрүгә контрольне көчәйтергә, ә район (шәһәр) судлары эшләрне вакытында карамаган очракта Татарстан Республикасы Югары Суды җитәкчелегенә шундый фактларны җиткерергә;

Ерак бара алу мөмкинлеге булмаган йөри алмаучы яки туганнары белән күрешү мөмкинлеге хокукын ала алмаган җәзаларны үтәтү урыннарында булган затларның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка төзәтү учреждениеләренә күчерү турында гозерен үтәү мөмкинлеген карарга.

8.2. Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгына Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенен Татарстандагы идарәсе һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә ирektән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүче ятим балалар исәбенә керүче гражданнарның, аларны торак шартларын яхшыртуда мохтаҗ булучы сыйфатында исәпкә кую гаризасын үзвакытында тапшырмау очракларын һәм бәхәсле хәлләрне булдырмау максатыннан, андый

гражданнар яшәп торган торакта аларга 23 яшь тулганга кадәр яшәү-яшәмәү мөмкинлекләре турында хәлләрне ачыклау буенча өстәмә чаралар күрергә.

С.Х. Сабурская,

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

Казан, февраль, 2017 ел

## ДОКЛАД УПОЛНОМОЧЕННОГО ПО ПРАВАМ ЧЕЛОВЕКА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

## О СОБЛЮДЕНИИ ПРАВ И СВОБОД ЧЕЛОВЕКА И ГРАЖДАНИНА В РСЕПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН В 2016 ГОДУ

Аппарат Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан
Адрес: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

Отпечатано в типографии «ЗурКазан».
Тираж 250 экз.
420095, г. Казань, ул. Серова, 4а
Тел.: (843) 253-58-33

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

## 2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН САКЛАУ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты
Адрес: 420015, Казань ш., К. Маркс ур., 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

«ЗурКазан» типографиясендә нәшер ителде.
Тираж 250 данә.
420095, Казань ш., Серова ур., 4а
Тел.: (843) 253-58-33